**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ СТАРОЗЮРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная 1А село Старые Зюри , 422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
E-mail: Szur.Tul @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

Мәктәп урамы, 1нчеА йорт, Иске Җөри авылы, 422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
E-mail: Szur.Tul @tatar.ru

**КАРАР**
**№1**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
21.01.2019 ел

Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлегендә белешмәләр, йорт кенәгәсеннән өземтә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдаланганда гражданнарга өстәмә гарантияләр булдыру өлешенә үзгәрешләр кертү турында»гы 2018 елның 19 июлендәге Федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге 131 санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1.Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 6 апреленең 4 санлы «Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлегендә белешмәләр, йорт кенәгәсеннән өземтә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында»гы карары белән (алга таба-карар) расланган Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлегендә белешмәләр, йорт кенәгәсеннән өземтә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына (алга таба –Регламент), 2.5 Муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандарты икенче юлының баганасына түбәндәге җөмләләрне өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүче орган гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган документларны башта кабул итмәгәндә, тиешле

мәгълүматларның булмавы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматларны таләп итәргә, яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән, түбәндәге очраклардан тыш, баш тартырга хокуклы түгел:

а) муниципаль хезмәт күрсәтүгә башта бирелгән гаризадан соң муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив-хокукый актлар таләпләре үзгәргәндә;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны башта кабул итмәгәннән соң бирелгән документларда хата, яки алдан бирелгән документлар комплектына кертелмәгән муниципаль хезмәт күрсәтү булганда;

в) документлар көченең срогы чыгу яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган документларны башта кабул итмәгәннән соң яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә мәгълүматлар үзгәрү;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 2010 елның 27 июлендәге 210 санлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлешендә күздә тоткан оешма хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны башта кабул итмәгәндә яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда документ белән расланган хаталы яки законга каршы гамәле (чара күрмәве) ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкчесе, күпфункцияле үзәк җитәкчесе яки 2010 елның 27 июлендәге 210 санлы Федераль законның 16 статьсы 1.1 өлешендә күздә тоткан оешма җитәкчесе гариза бирүчегә язмача хәбәр итә, шулай ук тудырган уңайсызлыклар өчен гафу үтенә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар буенча бастырырга.

3. Карар кул куелганнан соң көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольне үз өстемдә калдырам.

Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе

Р.Р.Мараков